СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Куркачи, ул. Клубная, 4

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур., 4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«19» ноября 2020 г.** **№ 10**

**“Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 декабрендәге 169 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында”**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында Федераль законнар, 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү турында, 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 декабрендәге 169 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Советның 07.02.2020 № 184 карары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчада «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;» сүзләрен өстәп тулыландырырга;

2) 6 статьясының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Г.Р.Закирова